МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____19.04.2018____ Казан ш. №____172____

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган Кара металлар, төсле металлар ломын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында
.

"Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган Кара металлар, төсле металлар ломын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 134 номерлы, 2015 елның 3 июлендәге 317 номерлы, 2016 елның 16 мартындагы 70 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 176 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 172 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган) кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлегенә (А.Т. Әмировага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.Д. Шәмсиевка йөкләргә.

**Министр Ф.С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
19.04.2018 172 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының
2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган
Кара металлар, төсле металлар ломын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген
лицензияләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы боерыгы белән расланган Кара металлар, төсле металлар ломын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 134 номерлы, 2015 елның 3 июлендәге 317 номерлы, 2016 елның 16 мартындагы 70 номерлы, 2016 елның 2 июнендәге 176 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 172 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган) (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

"Стандартка карата куелган таләпләрнең эчтәлеге" юлында:

2.5 пунктның 7 пунктчасындагы дүртенче абзацында "тапшырылуы турында белдерелә торган заказлы почта юлланмасы белән" сүзләрен "почта юлланмасы белән" мүзләренә алмаштырырга;

2.10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрендә бирелгән документка Министрлык һәм (яки) вазыйфаи зат, күпфункцияле үзәк һәм (яки) күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан җибәрелгән хатаны төзәтү өчен үзгәрешләр кертү очрагында, гариза бирүчедән түләү алынмый.";

2.13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Ял (бәйрәм) көнендә электрон почтага алынган мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.";

2.10 пунктның "Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт" юлына түбәндәге сүзләрне өстәргә: "210-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы";

3.1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

"3) техник хаталарны төзәтү.";

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучылар Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, Министрлык дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы оешмаларның яки аларның дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге шикаять бирү хокукына ия.

Шикаять Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысы булып торган гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) (алга таба - күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга кәгазьдә язма рәвештә бирелә. Татарстан Республикасы икътисад министрының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр шул күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысына яки Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затына бирелә. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр шул оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

5.2. Дәүләт хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучы түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучының дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, бирелергә мөмкин.

3) дәүләт хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыдан Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен каралмаган документлар таләп итү;

4) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы каралган документларны дәүләт хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыдан кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр дәүләт хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, аларны күрсәтүдән баш тарту; Күрсәтелгән очракта

күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, бирелергә мөмкин.

6) дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә дәүләт хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыдан Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы алар тарафыннан җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтмәләр кертү өчен билгеләнгән срокның бозылуы. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, бирелергә мөмкин.

8) дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылу;

9) әгәр дәүләт хезмәт күрсәтүне туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, аларны күрсәтүне туктатып тору; Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, бирелергә мөмкин.

5.3. Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, Татарстан Республикасы икътисад министрының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын (http://mert.tatarstan.ru), бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын (http://www.gosuslugi.ru/), йә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын (https://uslugi.tatarstan.ru/) файдаланып юллана ала, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтын, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын йә Татарстан Республикасының

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын файдаланып юллана ала, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, шул оешмаларның рәсми сайтларын, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын йә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын файдаланып юллана ала, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысына, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга йә югарырак органга (булган очракта) кергән шикаять – аны теркәгән көннән соң унбиш эш көне эчендә, ә Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документлар кабул итүдә йә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдә баш тартуына шикаять бирелгән очракта яисә мондый төзәтмәләр кертү өчен билгеләнгән срокның бозылуына шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза биргән физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр йә гариза биргән юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән гариза бирүченең килешмәве өчен нигез булган дәлилләр; Гариза бирүче үзенең дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда

җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләнгән акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Административ регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында аңлатмалы җавап язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булуы ачыкланган очракта, Административ регламентның 5.1 пунктының икенче абзацы нигезендә шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр тарафыннан булган бөтен материаллар кичекмәстән прокуратурага җибәрелә.".